***Роберт Миңнуллин***
***Әнием.***

Син, әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Елмайганда йөзләреңнән
Бар өйгә нур бөркелә.

Тыңлап бишек моңнарыңны,
Елавым басылган бит.
Телем дә минем иң әүвәл
“Әннә” дип ачылган бит.

“Иң матур сүз”
255б.

***Роберт Миңнуллин***
***Бутаган.***

Алмаз йөри урамда,
Эшләп йөри ул анда.
Чана шуу бар эше,
Ап-ак булган бар төше.

Ә мин аның Алмазга
Нигә өргәнен beләм:
Бутаган ул Алмазны
Аю баласы белән.

Акбай аны күргә,
Әй тотынды өрергә.
Аңламый Алмаз берни,
Өрерлек сәбәп күрми.

Башында – йонлач бүрек,
Өстендә дә йонлач тун.
Кем гаепле, ул үзе
Аю кебек булгачтын.

“Иң матур сүз”
238б.

***Роберт Миңнуллин***
***Игенчеләр гаиләсе.***

Әти ипи
Үстерә,
Әни ипи
Пешерә.
Ә мин...мин ипи
Ашыйм.
Ә аннары
Ипине
Үзем үстерә
Башлыйм.

“Балачак аланы”
389б.

***Роберт Миңнуллин***
***Ә үзләре...***

Зурлар безгә тапшыру да,
Кино да каратмыйлар.
- Ярамый да ярамый! – дип,
Көн саен кабатлыйлар.

- Кинолар кичен, - диләр, -
Олылар өчен! – диләр.

Әгәр дә карый башласаң,
Безгә бармак яныйлар...
Безгә дигән мультфильмны
Үзләре бик карыйлар!

“Балачак аланы”
483б.

***Роберт Миңнуллин***

***Туган илнең улы мин.***

Бабайның да
Улы мин,
Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин,
Аларның уң кулы мин.
Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын,
Бернигә дә карамый.
Шулай булмый
Ярамый –
Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

"Балачак аланы"
124б.

***Роберт Миңнуллин***

***Малайлар сөйләшә.***

- Мин үскәч абый булам!
Аннары бабай булам!
- Ә мин, бабай булгач та,
Гел әйбәт малай булам.
- Мин үзем әти булам!
- Ә мин дәү әти булам!
- Үскәч кем буласымны
Мин әле әйтми торам.
- Мин батыр солдат булам!
- Ә мин косманавт булам!
- Ә мин Третьяк булам!
Капкада сакта торам!..
- Ә мин бик озын булам,
Үсәм әле тагы да!
- Ә мин начальник булам,
Йөрим "Волгада"да гына!
- Ә мин кибетче булам
Яисә итче булам!
- Ә мин бик көчле булам,
Әтием төсле булам!
- Мин комбайнчы булам,
Кырда иген урырга!
- Ә миңа әни, үскәч,
Куша кеше булырга!

"Балачак аланы"
298б.

***Роберт Миңнуллин***

***Акбайга.***

Йөрмә, Акбай, безнең янда,
Йә тешләрсең, кит әле.
Песиебезгә дә өрмә -
Ул бәләкәй бит әле.
Юлбарыска охшаган ул
Безнең песи баласы.
Чынлап юлбарыс булган, ди,
Аның ерак бабасы.

Ул да үскәчтен юлбарыс
Булыр әле – күрерсең.
Алай бик батыр икәнсең –
Менә шунда өрерсең.

"Иң матур сүз"
141б.